**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 28 июль № 519

г. Казань

Татарстан Республикасы территориясендә күпфатирлы йортлардагы уртак мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыруга бәйле кайбер мәсьәләләр турында

Россия Федерациясе Торак кодексының 166 статьясындагы 4 өлеш, «Торак-коммуналь хуҗалыкны реформалаштыруга булышлык күрсәтү фонды турында» 2007 ел, 21 июль, ФЗ-185 нче Федераль законның $20^1$ статьясындагы 11 өлеш, Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында» 2013 ел, 25 июнь, ТРЗ-52 нче Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән түбәндәгеләрне расларга:

Татарстан Республикасы тарафыннан күрсәтелә торган дәүләт ярдәме акчасы исәбеннән финанслана ала торган күпфатирлы йортта уртак мөлкәтне капиталь ремонтлау буенча хезмәтләр һәм (яки) эшләр исемлеген;

«Торак-коммуналь хуҗалыкны реформалаштыруга булышлык күрсәтү фонды турында» Федераль законның $20^1$ статьясында билгеләнгән тәртиптә ачыла торган махсус счетлардагы акча исәбеннән күпфатирлы йортта уртак мөлкәтне капиталь ремонтлау буенча хезмәтләр һәм (яки) эшләр өчен түләү тәртибен.

2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 28 июль, 519 нчы карары белән расланды

**Татарстан Республикасы тарафыннан күрсәтелә торган дәүләт ярдәме акчасы исәбеннән финанслана ала торган күпфатирлы йортта уртак мөлкәтне капиталь ремонтлау буенча хезмәтләр һәм (яки) эшләр исемлеге**

1. Йорт эчендәге электр, җылылык, газ, су белән тәэмин итү, су бүлү инженерлык системаларын ремонтлау яки алыштыру, шул исәптән торак урыннарда урнашкан җылыту элементларын, шулай ук йорт эчендәге инженерлык системаларында булган механика, электр, санитария-техника җиһазларын ремонтлау яки алыштыру.

2. Эксплуатацияләү өчен яраксыз дип танылган лифт җиһазларын ремонтлау яки алыштыру, лифт шахталарын ремонтлау, лифтларны диспетчерлаштыру системасы белән җиһазландыру.

3. Түбәне ремонтлау, шул исәптән вентиляция ясалмый торган түбәне җилләтелә торган итеп ясау, түбәгә чыгу урыннары ясау.

4. Күпфатирлы йорттагы уртак мөлкәткә карый торган подвал урыннарын ремонтлау.

5. Фасадны җылыту һәм ремонтлау, халыкның аз хәрәкәтләнә торган төркемнәре өчен күпфатирлы йорттагы уртак мөлкәттән файдалана алу мөмкинлеген тәэмин итү максатларында, йортка керү урыннарын пандуслар белән һәм баскыч маршларын култыксалар белән ике яклап җиһазландыру.

6. Коммуналь хезмәтләр күрсәтү өчен кирәкле күмәк (йорт өчен уртак) ресурслар кулланылышын исәпләү җайланмаларын, әлеге ресурсларны (җылылык энергиясе, кайнар һәм салкын су, электр энергиясе, газ) куллану белән идарә итү һәм көйләү узелларын кую яки алыштыру.

7. Күпфатирлы йортның нигезен ремонтлау.

8. Күпфатирлы йортларга керү урыннарын ремонтлау.

9. Йорт яны территориясен видеокүзәтү системасы белән җиһазландыру.

10. Күпфатирлы йортка энергетика тикшеренүе үткәрү.

11. Проект документларына дәүләт экспертизасын әзерләү һәм үткәрү (проект документларын әзерләү шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы законнар нигезендә кирәк булса).

12. Төзелеш буенча тикшерүдә тотуны гамәлгә ашыру.

13. Күпфатирлы йортның янгыннан саклау системасын ремонтлау.

14. Күпфатирлы йортларны техник инвентарьлаштыру эшләрен үткәрү һәм техник паспортларны эшләү.

15. Күпфатирлы йортлардагы уртак мөлкәт составында конструкцияләрне һәм инженерлык системаларын капиталь ремонтлау эшләрен башкарганда, ремонтлана (алыштырыла) торган конструкцияләр һәм инженерлык системаларының

технологик һәм конструктив үзенчәлекләре нәтиҗәсендә сүтелгән яки җимерелгән, күпфатирлы йортлардагы уртак мөлкәт составына керми торган мөлкәт өлешләрен торгызу, шулай ук ремонт эшләре тәмамланганнан соң төзекләндерүне торгызу.

16. Күпфатирлы йортларга комплекслы капиталь ремонт ясалганда йорт яны территориясен төзекләндерү (балалар уен мәйданчыклары һәм спорт комплекслары урнаштырып).

17. Күпфатирлы йортлар фасадларында социаль реклама урнаштыру.

F:\KARAR\2016\519.docx

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 28 июль, 519 нчы карары белән расланды

**«Торак-коммуналь хуҗалыкны реформалаштыруга булышлык күрсәтү фонды турында» Федераль законның 20[1] статьясында билгеләнгән тәртиптә ачыла торган махсус счетлардагы акча исәбеннән күпфатирлы йортта уртак мөлкәтне капиталь ремонтлау буенча хезмәтләр һәм (яки) эшләр өчен түләү тәртибе**

1. Әлеге «Торак-коммуналь хуҗалыкны реформалаштыруга булышлык күрсәтү фонды турында» Федераль законның 20[1] статьясында билгеләнгән тәртиптә ачыла торган махсус счетлардагы акча исәбеннән күпфатирлы йортта уртак мөлкәтне капиталь ремонтлау буенча хезмәтләр һәм (яки) эшләр өчен түләү тәртибе (алга таба – Тәртип) күпфатирлы йорттагы уртак мөлкәтне капиталь ремонтлау буенча хезмәтләр күрсәтүче һәм (яки) эшләр башкаручы затларга (алга таба – подряд оешмалары) күпфатирлы йорттагы уртак мөлкәтне капиталь ремонтлау буенча хезмәтләр күрсәтүгә һәм (яки) эшләр башкаруга шартнамәләр (алга таба – подряд шартнамәсе) буенча, «Торак-коммуналь хуҗалыкны реформалаштыруга булышлык күрсәтү фонды турында» 2007 ел, 21 июль, ФЗ-185 нче Федераль законның (алга таба – Федераль закон) 20[1] статьясындагы 8 өлеше нигезендә торак милекчеләре ширкәтләре яисә торак-төзелеш кооперативлары, торак кооперативлары яки күпфатирлы йортлар белән идарә итүне гамәлгә ашыра торган башка махсуслаштырылган кулланучылар кооперативлары, әгәр тиешле идарә итүче оешмага яки төбәк операторына күпфатирлы йортлардагы урыннар милекчеләренең уртак җыелышы карары буенча алар белән төзелгән шартнамәләр нигезендә капиталь ремонт буенча төбәк программасын тормышка ашыруның кыска вакытлы планында каралган әлеге йортларга капиталь ремонт ясауны оештыру йөкләнгән булса, идарә итүче оешмалар, төбәк операторы (алга таба – махсус счет хуҗалары) тарафыннан ачылган аерым банк счетларыннан акча күчерү нигезләрен, шартларын һәм вакытларын билгели.

2. Күпфатирлы йортларга капиталь ремонт ясау өчен юнәлдерелә торган дәүләт корпорациясе – Торак-коммуналь хуҗалыкны реформалаштыруга булышлык күрсәтү фонды акчасы, Татарстан Республикасы бюджеты акчасы һәм (яки) җирле бюджетлар акчасы исәбеннән өлешле финанслау акчасы Федераль законның 18 статьясындагы 2 өлештә бигеләнгән минималь күләм чикләрендә Россия Федерациясе Торак кодексының 166 статьясындагы 1 өлештә һәм Россия Федерациясе Торак кодексының 166 статьясындагы 2 өлеш нигезендә кабул ителгән Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында күрсәтелгән күпфатирлы йорттагы уртак мөлкәтне капиталь ремонтлау буенча хезмәтләр һәм (яки) эшләрне финанслау өчен генә файдаланыла ала.

3. Федераль законның $20^{1}$ статьясындагы 7 өлештә күрсәтелгән счетларга салынган акча махсус счет хуҗалары тарафыннан подряд оешмаларына түбәндәгеләр нигезендә күчерелә:

1) күпфатирлы йорттагы урыннар милекчеләренең уртак җыелышының күпфатирлы йортта уртак мөлкәтне капиталь ремонтлау буенча хезмәтләр күрсәтү турында һәм (яки) эшләр башкару хакында карарын үз эченә алган әлеге җыелыш беркетмәсе;

2) подряд шартнамәсе;

3) җирле үзидарә органнары белән килештерелгән һәм, Федераль законның $20^{1}$ статьясындагы 14 өлештә билгеләнгән очрактан тыш, күпфатирлы йорттагы урыннар милекчеләре исеменнән гамәлләр кылу вәкаләтләре бирелгән затлар тарафыннан имзаланган подряд шартнамәсе буенча күрсәтелгән хезмәтләрне һәм (яки) башкарылган эшләрне кабул итү акты. Әлеге кабул итү акты хезмәтләр күрсәтүгә һәм (яки) эшләр башкаруга подряд шартнамәсе буенча бу хезмәтләр һәм (яки) эшләр кыйммәтеннән иң күбе 30 процент күләмендә аванс түләү операциясен башкарган очракта бирелми.

4. Подряд шартнамәләре буенча акча махсус счет хуҗалары тарафыннан турыдан-туры подряд шартнамәсендә күрсәтелгән подряд оешмаларының хисап счетларына күчерелә.

5. Банк счетларына салынган һәм Федераль законның $20^{1}$ статьясындагы 10 өлештә күрсәтелгән акча, Федераль законның $15^{1}$ статьясындагы 3 өлештә билгеләнгән таләпләрне исәпкә алып, әлеге акчаның иң күбе 30 проценты күләмендә күпфатирлы йортны капиталь ремонтлау буенча хезмәтләр күрсәтүгә һәм (яки) эшләр башкаруга аванс түләү өчен файдаланыла ала.

6. Подряд оешмаларына акчаны, шул исәптән аванс түләүләрен күчерү подряд шартнамәсендә каралган вакытларда гамәлгә ашырыла.

___